Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
«Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Аккуҗа торак
пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**14.11.2025** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 14 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта "Әгерҗе муниципаль районының « Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Аккуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле) һәм аларның бергә яшәүче гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, хатын, балигъ булган балалар) тыш, 2026 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Яңа Аккуҗа авылында урамнарны яктыртуны карап тоту, хезмәт килешүе буенча электрикка түләү һәм урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар);

- торак пункт территориясен төзекләндерү ( Яңа Аккуҗа авылында юлларны кардан чистарту, чүп үләннәрен чабу, МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү өчен су савыты сатып алу һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар);

- каты көнкүреш калдыкларын туплау өчен мәйданчыклар булдыру, контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Яңа Аккуҗа торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекне бетерү

башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?" дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« РИЗА» «КАРШЫ».

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 138 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 74 кеше, бу 54% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 74 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Аккуҗа торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Әгерҗе муниципаль районы « Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Аккуҗа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр) һә м аларның гаилә әгъзаларыннан ( ата-аналары, ире яки хатыны), I төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны

гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Яңа Аккуҗа авылында урамнарны яктыртуны карап тоту, хезмәт килешүе буенча электрикка түләү һәм урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар);

- торак пункт территориясен төзекләндерү ( Яңа Аккуҗа авылында юлларны кардан чистарту, чүп үләннәрен чабу, МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү өчен су савыты сатып алу һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар);

- каты көнкүреш калдыкларын туплау өчен мәйданчыклар булдыру, контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Яңа Аккуҗа торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекне бетерү).

4.Карарны Тәбәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) , «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Салимуллин

Совет Табарлинского сельского поселения
Тәбәрле авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002519